СОВЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Мәктәп урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar.ru.

**Шушмабаш авыл җирлеге Советы**
**карары**

**29 гыйнвар 2024 ел** **№120**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылында урам исемен үзгәртү турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставына ярашлы рәвештә, үтенечнамә нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Шушмабаш авыл җирлеге территориясендәге Шушмабаш авылында Мәктәп урамын, үзгәртелгән урамда адрес номерларын саклап, Габделхәй Кәримов урамы дип үзгәртергә.

2. Дәүләт адрес реестрына адресны кертергә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Шушмабаш авыл җирлеге, Шушмабаш авылы, Габделхәй Кәримов урамы.

3. Шушмабаш авыл җирлеге башкарма комитетына бер ай эчендә йөкләргә:

-Шушмабаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларның урам исемнәре реестрына үзгәрешләр кертергә;

- исемен үзгәрткән урамда адрес атрибутикасын урнаштыруны тәэмин итәргә;

- әлеге карарны гамәлгә ашыру буенча башка чараларны гамәлгә ашырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru), Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы, Арча районы, Шушмабаш авылы, Мәктәп урамы, 1Б йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Носы авылы, Татарстан урамы, 45 йорт адреслары буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Шушмабаш авыл җирлеге башлыгы В. В. Сәгыйтов

СОВЕТ ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН · АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН · МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ШУШМАБАШСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» · ОГРН1121690000210
ИНН1609012678